**МКУ «УПРАВЛЕНИЕ ОБРАЗОВАНИЯ»
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
423740 с. Актаныш, пр. Ленина, 17
тел./факс 3-09-07

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
МКУ «МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ»**
423740 Актаныш авылы, Ленин пр-ты, 17 тел /факс 3-09-07

# ПРИКАЗ

№449-ОД от 19.11.2021 г.

## О проведении районного конкурса «ТАТАР ЕГЕТЕ, ТАТАР КЫЗЫ – 2021»

На основании плана работы МКУ «Управление образования» Актанышского муниципального района и в целях реализации творческого потенциала воспитанников и учащихся образовательных учреждений, выявление и поддержки среди татарской молодежи, расширение круга интересов, содействия в удовлетворении ими духовных, интеллектуальных, творческих и социальных потребностей, ПРИКАЗЫВАЮ:

1. 9-10 декабря 2021 г. провести конкурс на муниципальном уровне среди воспитанников дошкольных образовательных учреждений и учащихся общеобразовательных учреждений.
2. Рекомендовать руководителям образовательных учреждений:

2.1. Ознакомиться с порядком проведения Конкурса (Приложение №1).

2.2. Организовать дошкольные и школьные этапы Конкурса, определить победителей.

2.3. Обеспечить участие в районном этапе Конкурса.

2.4. Заявки на участие в муниципальном этапе предоставить до 6 декабря 2021 г. в МКУ «Управление образования» Хисматуллиной Л.Ф., Имамовой Р.А., Имамразыевой Г.Д. (Приложение №2)

3. Информацию о проведении конкурса разместить на сайтах образовательных организаций.
4. Контроль за исполнением настоящего приказа возложить на Г.Д.Имамразыеву, заместителя начальника по учебно-методической работе

Начальник Р.М.Шакирова

“Мәгариф идарәсенең” 19.11.2021 чыккан
№ 449 – ОД приказына 1 нче Кушымта

**«ТАТАР ЕГЕТЕ, ТАТАР КЫЗЫ - 2021» район бәйгесе**
**ПОЛОЖЕНИЕСЕ**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге нигезләмә «Татар егете, Татар кызы - 2021» район бәйгесен (алга таба – Бәйге) үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Бәйгене Актаныш муниципаль районы «Мәгариф идарәсе» оештыра.

**2. Бәйгенең максаты һәм бурычлары**

2.1. Яшь буынның ата-бабаларыбызның тарихи-мәдәни мирасына карата кызыксынуларын арттыру, яшьләрдә гаилә һәм милли кыйммәтләргә карата хөрмәт тәрбияләү, сәламәт яшәү рәвешенә тарту.

2.2. Милли йолаларның, гореф-гадәтләрнең үзенчәлеген ассызыклау, хәзерге мәдәни тирәлектәге урынын билгеләү, милләтара мөнәсәбәтләрне формалаштыруда аларның әһәмиятен ачыклау.

2.3. Талантлы балаларга, яшьләргә иҗади потенциалларын тормышка ашыруда ярдәм итү.

2.4. Бәйгедә катнашучыларның тәҗрибәләрен яңа белемнәр, күнекмәләр һәм тәэсирләр белән баету.

2.5. Башка милләт вәкилләренең татар халык мәдәниятен өйрәнүгә кызыксынуларын арттыру.

**3. Бәйгедә катнашучылар**

3.1. Бәйгедә Актаныш муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучылары һәм балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр катнаша.

3.2. Яшь категорияләре буенча бүленеш түбәндәгечә:

- балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр,
- башлангыч сыйныф укучылары,
- 5-8 сыйныф укучылары,
- 9-11 сыйныф укучылары.

**4. Бәйгене үткәрү вакыты һәм этаплары**

4.1. Бәйге 2021 елның 29 ноябреннән 10 нчы декабрь аралыгында үткәрелә.

4.2. 2021 елның 6 декабренә кадәр район этабында катнашу өчен гаризалар кабул ителә.

4.3. 9, 10 декабрь көннәрендә «Балалар иҗат үзәге» базасында район этабы үткәрелә.

**5. Бәйгене үткәрү тәртибе**

5.1 Бәйгедә катнашырга теләк белдерүчеләр түбәндәге биремнәрне башкарырга тиеш:

**«Мин бит татар баласы...» темасы астында визит карточкасы әзерләү**

Катнашучылар төрле чаралар кулланып үзләрен тәкъдим итәләр. 3 кешедән артмаган ярдәм төркеме (группа поддержки) катнаша ала. Визитканың регламенты - 3 минут.

| Визиткаларны бәяләү | |
|---|---|
| - чыгышның эчтәлеге, эзлеклелеге | 0 – 5 балл |
| - конкурсның тематикасын ачу | 0 – 5 балл |
| - гореф-гадәтләрне заманча күзлектән тәкъдим итү, ачу | 0 – 5 балл |
| - чыгышның эстетик бизәлеше | 0 – 5 балл |
| - чыгышның оригинальлеге | 0 – 5 балл |
| | 25 балл |

Визит карточкасын **Иҗади бәйге** дәвам итә (регламент – 3 минут). Теманы ачып җыр, бию, шигъри әсәр һ.б.башкарырга мөмкин.

| Иҗади конкурсны бәяләү | |
|---|---|
| - чыгышның оригинальлеге | 0 – 2 балл |
| - чыгышның эчтәлеге, темага туры килүе | 0 – 2 балл |
| - саф татарча сәнгатьле сөйләм | 0 – 2 балл |
| - башкару осталыгы, артистизм | 0 – 2 балл |
| | 8 балл |

**«Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс»**

Конкурсантлар үзләре әзерләгән кул эшләнмәләрен (пешкән ризык, тегелгән-чигелгән, агачтан ясалган кул эшләнмәсе һ.б.) яклыйлар

| Кул эшләнмәләрен бәяләү | |
|---|---|
| - эшләнмәнең тышкы кыяфәте, бизәлеше | 0 – 3 балл |
| - оригиналь рәвештә тәкъдим итү | 0 – 3 балл |
| - эшләнү (әзерләү) процессын тулысынча чагылдыру | 0 – 3 балл |
| | 9 балл |

**«Гыйлем – кояш, акыл - канат» интеллектуаль тест**

Татарстан һәм татарлар тарихы, милли йола-бәйрәмнәр, гореф-гадәтләрнең килеп чыгышы, татар теле, шигърияте, мәдәнияте белән бәйле сораулар, биремнәр.

**6. Нәтиҗәләр чыгару һәм бүләкләү**

6.1. Жюри карары нигезендә бәйгедә катнашучылыр 3 призлы урынга бүленә һәм Җиңүче грамотасы белән бүләкләнә.

6.2. Оештыру комитеты карары нигезендә катнашучыларны өстәмә номинацияләрдә бүләкләү каралган.

6.3. Бәйгедә катнашучылар катнашучы сертификаты белән бүләкләнә.

"Мәгариф идарәсенең" 19.11.2021 чыккан
№ 449 – ОД приказына 2 нче Кушымта

«ТАТАР ЕГЕТЕ, ТАТАР КЫЗЫ - 2021» бәйгесенең жюри әгъзалары

1. Шакирова Р.М., «Мәгариф идарәсе» җитәкчесе, жюри рәисе;
2. Имамразыева Г.Д., «Мәгариф идарәсе»нең укыту-методик эшчәнлек буенча урынбасары;
3. Мусина Г.М., «Мәгариф идарәсе»нең тәрбия эшләре буенча урынбасары;
4. Хисматуллина Л.Ф., мәктәпкәчә тәрбия методисты;
5. Хафизова Т.М., «Аерым фәннәрне тирәнтен үзләштерүле Актаныш икенче урта гомуми белем бирү мәктәбе» татар теле һәм әдәбияты укытучысы, район методик берләшмә җитәкчесе;
6. Борһанова Г.Д., «Аерым фәннәрне тирәнтен үзләштерүле Актаныш икенче урта гомуми белем бирү мәктәбе» татар теле һәм әдәбияты укытучысы;
7. Галиева Л.Р., «Актаныш беренче санлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» татар теле һәм әдәбияты укытучысы;
8. Шарипова Ч.Р., «Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат» гомуми белем бирү учреждениесе татар теле һәм әдәбияты укытучысы
9. Салахов Р.З., «Байсар төп гомуми белем бирү мәктәбе» татар теле һәм әдәбияты укытучысы, «Директорлар Советы» җитәкчесе.